КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 февраль г.Казань № 99

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 май, 574 нче карары белән расланган Хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару мәйданчыкларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару мәйданчыкларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 6 май, 574 нче карары белән расланган Хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару мәйданчыкларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның беренче абзацында «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы программасы» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның бишенче абзацында «4.11» саннарын «4.10» саннарына алмаштырырга;

2.3 пунктның егерме сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (сайлап алуда катнашучының имзасы һәм мөһер (булганда) белән расланган төзәтүләрдән тыш) рөхсәт ителми. Документларның һәр битенә бит саны куелган, тегелгән, сайлап алуда катнашучының имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш.»;

2.4 пунктның икенче абзацында «мөһере» сүзеннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

4.8 пунктның тугызынчы абзацына «(булганда)» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин